**Кеше булган кешедә мең кешенең эше бар...**

Г.Ф.Магданурова
Актаныш муниципаль районы Мари-Суыксу урта белем бирү мәктәбе

**Кереш.**

Татарстанның халык шагыйре Гамил Афзалның иҗат һәм тормыш юлын миңа күп тапкырлар күздән кичерергә туры килде. Аның шигырьләрен бик яратып укыдым, төрле кичәләрдә сөйләдем. Ә "Авыл" шигыренә язылган җыр исә гаиләбезнең, туганнарыбызның иң яраткан җыры булып кала бирә.

Шагыйрь иҗатын тирәнрәк өйрәнгән саен мин аның хезмәтенең кабатланмас иҗат, кеше күңелен әсир итә алырлык көчкә ия милли дә, иманлы да иҗат булуына ышандым.

Г.Афзал тормышы һәм иҗат мирасы 20 гасыр татар поэзиясен, һәм гомумән ил, әдәбият тарихын, халык язмышын аңлауда "ачкыч"булып тора.

Аның шигырьләре җиңел укыла, иҗади фикер аңлашыла, әдәби образ ачык сурәтләнеп күз алдына килеп баса. Кайбер шигырьләрендә шагыйрьнең тормыш тәҗрибәсе тулысынча күренә, акылы, сәяси тоемы, өлешчә көрәзәчелеге дә сокландыра. Күп шигырьләрендә шагыйрьнең чиксез хисле кичерешләре сине әсир итә, ә тагын бик күпләре сине ирексездән елмаерга мәҗбүр итә, рәхәтләнеп көлдерә дә. "Бәхет", "Киңәш", "Чәй янында" шигырьләре нәкъ менә шундыйлардан.

Әдәби тәнкыйтьтә Г.Афзалның аерым шигырьләренә, шигъри җыентыкларына бәя биргән мәкаләләр, рецензияләр бик күп. Аның шигъриятен, тормыш юлын өйрәнүгә Н.Юзеев, Т.Галиуллин, Н.Хисамов, А.Яхин кебек галимнәр зур өлеш кертсә, иҗат үзенчәлекләрен өйрәнүдә һәм билгеләүдә С.Хәким, Ф.Шәфигуллин, Р.Мостафин, Р.Төхфәтуллин, Р.Фәйзуллин, Р.Әхмәт, Р.Гаташ, Г.Гыйльманов, А.Хәлим күзәтү-эзләнүләре аерым урын тота.

**Төп өлеш.**

Шагыйрь иҗаты башлыча аның аерым китапларына яки конкрет әсәрләренә кереш сүз яки бәяләмә бирү, кайбер әсәрләренең идея-эстетик тематик үзенчәлеген аңлау, сәнгатьле сурәт алымнарын барлау һәм татар әдәбиятына алып килгән яңалыгын билгеләү юнәлешендә яктыртылган. Г.Афзал иҗатының үзенчәлеген билгеләү юнәлешендә язылган аерым язмаларда һәм мәкаләләрдә ике тенденцияне аерып карарга мөмкин. Бер төркем тәнкыйтьчеләр һәм каләмдәшләренең язмалары Г.Афзал иҗатын икегә: лирика һәм юмор-сатирага аерып өйрәнү, шагыйрьнең талантын күбрәк көлке сферасы белән бәйләп аңлатуга кайтып кала, ләкин бу карашларны кире кагучылар, һәр ике өлкәдә дә Г.Афзалның иҗат үзенчәлеге бердәй яңгыраш табуын билгеләп үтүчеләр дә шактый.

Беренче юнәлеш барлыкка килү 1958 нче елда Г.Афзалның икенче шигырьләр җыентыгы - "Вөҗдан сүзе"нең басылып чыгуы белән бәйле. Бу җыентыкны укып чыккач, күренекле тел галиме Н.Юзиев "татар поэзиясендә яңа шагыйрь туды" дип язып чыга. (1981, 258-259). Шагыйрьнең "Вөҗдан сүзе" җыентыгына тупланган лирик шигырьләрен Р.Гайнанов юмор-сатира әсәрләреннән аерып куя. (1959,121).

Г.Афзалның "Өф-өф"итеп (1968) дип исемләнгән, юмор-сатира шигырьләре тупланган җыентыгы турында С.Хәким : "Г.Афзал иҗатында лирика үзенә аерым жанр, юмор, сатира үзенә аерым жанр, алар бер-берсе белән кушылмыйлар, сатираның лирика белән компромисска барасы килми"- дип билгеләп үтә. Шул рәвешле тәнкыйть шагыйрьне күбрәк юмор-сатира остасы буларак таный, шул жанр кысаларында иҗат иткән шигырьләрен тикшерүгә һәм бәяләүгә әһәмият бирә. Мәсәлән: "Мыек борам", "Тун астында кыюлык" шигырьләре.

Ләкин шагыйрьнең җитди шигырьләре дә читләтеп үтелми. Нил Юзиев шагыйрьнең үзенчәлекле шигъри фикерләве, кабатланмас шигъри дөньясы ачылуы турында язып чыкса, шагыйрь иҗатында лирика белән юмор-сатираның үрелеп баруы, "поэзиясенең бербөтенлеге" турында

Т.Галиуллин, Н.Хисамов, А.Яхин, Ф.Шәфигуллин, Р.Әхмәт кебек әдәбият галимнәре һәм белгечләре, каләмдәшләре тарафыннан билгеләп үтелә.

Г.Афзал иҗатын өйрәнүдә икенче юнәлешне шигъриятенең аерым сыйфатларына тукталу, лирика яки юмор-сатирасының кайбер үзенчәлекләрен билгеләү, сәнгатьле сүрәт алымнарын барлау, аерым әсәрләренә күзәтү ясау, бәяләү тәшкил итә. Аның иҗатын өйрәнүгә күп көч куйган, шагыйрьнең әдәби остазы С.Хәким һәм әдәбият галиме Н.Юзиев – беренче бәяләүчеләре дә. Г.Афзалның яшь буынга багышланган “Кар сулары”җыентыгы (1957) басылып чыгу уңаеннан дөнья күргән Н.Юзиевнең “Яшь шагыйрьнең беренче китаб ы”мәкаләсе бу юнәлештәге беренче тәнкыйди материал булып тора. Әдәбият галиме шагыйрьнең шигърияткә килү юлы, юнәлешләренә һәм Г.Афзалның балалар поэзиясенә игътибар биреп, шигырьләрнең тематикасы, поэтикасы, сәнгатьчә эшләнеше мәсьәләләрен күтәреп, иҗатына җентекле анализ ясый.

Г.Афзалның халык арасындагы шөһрәте шагыйрьнең халыкчанлыгы, татар сатирасы классиклары Г.Тукай, Ш.Бабичларның шигъри традицияләре дәвамлылыгына бәйләп карала һәм иҗатының үзенчәлеге шуның белән аңлатыла. Галим Н.Ш.Хисамов, С.Хәким фикерләренә таянып, Тукай шигърияте җирлегендә үсеш алган, милли сатираны баетуга китергән яңарак шигъри алымнарны билгеләп үтә. Н.Ш.Хисамов “Минем сакал”, “Сәләхетдин бабай сүзләре”, “Мәгъфия әбинең догасы” шигырьләрен җентекләп тикшерә.

Г.Афзал иҗатында халык иҗаты традицияләре дәвамлылыгын соңрак фәнни яссылыкта Т.Н.Галиуллин һәм Л.Ә.Кәшфиева тикшерә.

Әдәбият галиме, тәнкыйтьче Т.Галиуллинның халык иҗаты һәм поэзия мөнәсәбәте мәсьәләләрен фәнни яссылыкта тикшергән “Илһам чишмәләре” монографиясе аерым игътибарга лаек. Галим бу хезмәтендә шигырьләрдә халыкчан җирлек, фольклор белән тыгыз бәйләнешне, шагыйрьнең эстетик фикерләвен, әдәби осталыгын, поэтик үзенчәлеген билгеләп үтә.

Әдәбият галиме А.Г.Яхинның Г.Афзал иҗатында чор һәм шәхес каршылыгы, хакыйкать темасының бирелеш үзенчәлеге, автор һәм лирик герой мөнәсәбәтләре кебек мәсьәләләрне тикшерүе шагыйрь иҗатын өйрәнүне тирәнәйтүгә ярдәм итә.

Г.Афзал иҗатын даими күзәтеп, бәяләп барган әдәбият галиме Т.Н.Галиуллинның шагыйрь поэзиясенең төп үсеш-үзгәреш чорларын һәм юнәлешләрен билгеләвен дә күләмле һәм бик кирәкле хезмәт дип бәяләргә кирәк. Әлеге галим тарафыннан Г.Афзал шигърияте шартлы дүрт чорга бүленеп карала, бу чорларга туры килгән әсәрләре күрсәтелә:

1.Рәнҗетелгән күңел сагышы.(50-60 нчы еллар)

2.Күңел көрлеге сагышы.(60-70 нче еллар)

3.Тарихи аң сагышы.(80 нче еллар)

4.Фәлсәфи уйланулар сагышы.(90 нчы еллар)

Күренекле язучы Г.Гыйльманов тарафыннан Г.Афзал шигъриятендә урман, тау, җил,күк кебек образларның эчтәлеге, мәгънәви кыры ачыклана, күзәтүләр ясала. Чыннан да шагыйрь табигать образлары белән оста эш итә. Аларга катып калган образлар итеп кенә карамый, бәлки җан өрергә тырыша, хыял көче белән аларның рухын кайтармакчы була һәм бу хакта үзе “Ак болытлар ага” исемле парчасында ачыктан-ачык яза:

Хыялыңда дөнья йөзен буйла,
Изге хисләр сиңа иярсен.
Табигатьнең җаны-мин, дип уйла,
Биек-биек тауга менәрсең.

Г.Афзал шигъриятен, әсәрләрнең сәнгатьчә төзелү осталыгын, сүрәтләү чараларының үзенчәлеген Р.Хөрмәтуллина тарафыннан башкарыла, аның хезмәте күләмле гыйльми хезмәт буларак билгеле.

## Йомгаклау.

Г.Афзал иҗатын өйрәнү, аның татар әдәбиятында тоткан урынын дөрес бәяләү, шигъриятенә хас үзенчәлекләрен билгеләү юнәлешендә әдәбият галимнәре тарафыннан күләмле, җитди эш башкарылган.Г.Афзалның башлангыч чорыннан алып соңгы елларга кадәр иҗатын тикшерү-бәяләү, өйрәнү аның иҗатын тиешенчә ачыклаган.

Дөнья хәлләрен үткен фикер аша уздырып карау сәләтенә ия, киң карашлы, үзенчәлекле лирик һәм сатирик шагыйръ Г.Афзал иҗаты галимнәр тарафыннан әдәбиятта үзгәреш-яңарышларны әйдәп баручы иҗат дип бәяләнә.

Г.Афзал иҗатын үзәккә алып өйрәнгән әдәбият галиме Н.Г.Юзиевкә шагыйрь язган хаттан түбәндәге юллар белән чыгышымны тәмамлыйм: “Иҗат. Бу бит чәч очыннан башлап аяк бармаклары очына кадәрле булган барлык нерв күзәнәкләренең бердәм тартылып тыңлаган, эшләгән вакыты. Шагыйрьнең көрәзәчелек иткән вакыты, аның кодрәте белән Аллага тиң вакыты”. Якташ шагыйребезнең иҗат мирасы онтылмасын. Әдәбиятыбыз, сәнгатебез яшәсә генә, телебез һәм милләтебез яшәр.

## Файдаланылган әдәбият:


1. Афзал Г.Г. Өф-Өф итеп: Сатира-юмор шигырьләре. - Казан: Татар кит.нәшр.-187б.
2. Афзал Г.Г. Ышаныгыз: сайланма шигырьләр. - Казан: Татар кит.нәшр.-288б.
3. Гайнанов Р. Гамил Афзал шигырьләре. – Совет әдәбияты.-188б.
4. Галиуллин Т.Н. Илһам чишмәләре: Монография. – Казан: Татар кит.нәшр.-365б.
5. Юзиев Н.Г. Шигърият дөньясы: Тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар.кит.нәшр.-312б.